# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“30” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 30 мартында 11 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Дусым авылының Ш.Камал урамына янгынга каршы гидрант урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы өчен өстәмә уен инвентарьлары, төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).”

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 155 (бер йөз илле биш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 81 (сиксән бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 81 (сиксән бер) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Дусым торак пунктында гражданнар Җыенының 17.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (Дусым авылының Ш.Камал урамына янгынга каршы гидрант урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы өчен өстәмә уен инвентарьлары, төзелеш материаллары сатып алу, урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).”

мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Дусым авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.